Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

«25"   март   2019  ел                                                                                    №32

Капиталь төзелеш объектларын төзүнең,
реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән
иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга
рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елның 14 февралендәге  07  номерлы «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»гы карары нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. «ДОМКОР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын түбәндәге чараларны билгеләү өлешендә реконструкцияләүгә рөхсәт бирергә:

- кишәрлекнең ян сызыгыннан корылмаларның минималь чигенеше (кадастр номеры  16:45:050112:391) - - 6 м, җир кишәрлеге ягыннан

- кишәрлекнең ян сызыгыннан (кадастр номеры  16:45:050112:383 булган җир кишәрлеге ягыннан) - - 9 м,

- корылмаларның арткы чиктән минималь чигенеше - 8 м,

Катлар - "5 дән 10" га кадәр

2. «Әлмәт муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына (Пузырева И.Г.) җибәрергә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә  (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанова  йөкләргә.

Шәһәр Башкарма  комитеты җитәкчесе                                              Л.Ф. Валеев